**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 22 маендагы 1578 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 19 мартындагы 777 номерлы «Казан шәһәре Вахитов районының Гоголь урамында һәм Подлужная урамында ачык сервитут билгеләү турында»гы карарына үзгәреш кертү хакында**

Техник хаталар җибәрелүгә бәйле рәвештә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 19 мартындагы 777 номерлы «Казан шәһәре Вахитов районының Гоголь урамында һәм Подлужная урамында ачык сервитут билгеләү турында»гы карарына, 2 номерлы кушымтаны әлеге карарның кушымтасы нигезендәге редакциядә биреп, үзгәреш кертергә.

2. «Казанны үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карар нигезендә ачык сервитутның йогынты ясау өлкәсе турында тиешле мәгълүмат кертү өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итәргә.

3. Әлеге карарны, кушымтасыннан кала (хезмәт урынында файдалана торган материал), «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**